*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________ Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2015-2016 учебный год**
**9 класс**

**I. Рус телендәге гыйбарәләрнең татарча әйтелешен языгыз. /** Напишите выражения, соответствующие русским.(10 баллов).

1) **Была не была -**
2) **В том-то и дело -**
3) **Все прекрасно -**
4) **Делай с умом -**
5) **Ничего особенного -**
6) **Приятного аппетита -**
7) **С удовольствием -**
8) **Будь на чеку -**
9) **Скажи откровенно -**
10) **Черт знает -**

**II. Күп нокталар урынына тиешле кушымчаларны куегыз./** Вместо многоточий вставьте нужные окончания (5 баллов).

2016 нчы елда Татарстанда 95 мәктәп һәм 52 мәктәпкә...... белем бирү учреждение.... төзекләндерү планлаштырылган. ТР Дәүләт торак инспекция...... мәгълүматларына караганда, 2015 елда 42 муниципаль районда капиталь ремонт...... торган күп фатирлы йортларда инспекция тикшерүе үткәрелгән. 2016 елда балаларны савыктыру лагерь...... 9 ында капиталь ремонт ясау планлаштырылган. *(вакытлы матбугаттан)*

**III. Бирелгән теksттан 5 пар антонимны табып язып алыгыз. /** Выпишите из текста 5 пар антонимов. (10 баллов)

...Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шул чаклы сиздерә дә башлар икән. Кичен ни көтәсе инде?! Гаҗәп! Хәтта төне дә җиңеллек китермәде – суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан исен аңкытып, һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Менә өч атна инде әле яңгыр тамганы юк. Температура көндезен утыздан артып китә, төннәрен егермедән дә төшми диярлек. Бер кат җәймә генә ябынып ятсаң да йоклап китә алмыйча азапланып бетәсең, мендәреңнең салкынчарак җирен эзләп, аны кат-кат әйләндерергә мәҗбүр буласың. Кышкы суыктан да әшәкерәк икән ул бөркү эсселек!.. (Ә.Еники*дән)*

________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________
________________________________________________________________________

**IV. Һәр җөмләгә тулы билгеләмә бирегез. /** Дайте полное определение каждому предложению. (10 баллов)

1) Ул арада чәй дә кайнап чыга. 2) Табын янына утырасың, табыннан җылылык, нур бөркелә. 3) Каян килә ул нур, ул җылылык? 4) Тәрәзә төбендәге гөлләрдәнме? 5) Әллә инде

пар бөркеп утырган самавырданмы? 6) Белмәссең... 7) Ә күңелдә әнә шул җылылыгы, нуры белән бергә моң да бар. 8)Әйтү, аңлату мөмкин булмаган моң газаплый. 9) Шуны куарга, онытырга теләгәндәй, сүз башлыйм.

10) - Һаман дөнья куасыз инде, ә? *(Р. Мөхәммәдиевтән)*

**1)**________________________________________

**2)**________________________________________

**3)**________________________________________

**4)**________________________________________

**5)**________________________________________

**6)**________________________________________

**7)**________________________________________

**8)**________________________________________

**9)**________________________________________

**10)**_______________________________________

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов)

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | **А** | | | | | | | | | |
| **2** | **А** | | | | | | | | | |
| **3** | **А** | | | | | | | | | |
| **4** | **А** | | | | | | | | | |
| **5** | **А** | | | | | | | | | |
| **6** | **А** | | | | | | | | | |
| **7** | **А** | | | | | | | | | |
| **8** | **А** | | | | | | | | | |
| **9** | **А** | | | | | | | | | |
| **10** | **А** | | | | | | | | | |
| **11** | **А** | | | | | | | | | |
| **12** | **А** | | | | | | | | | |
| **13** | **А** | | | | | | | | | |
| **14** | **А** | | | | | | | | | |
| **15** | **А** | | | | | | | | | |

1. Күк җисеме
2. Өлкән ир туган
3. Халык исеме
4. Сөйләмнең иң кечкенә берәмлеге
5. Нинди дә булса бер хезмәтнең иҗатчысы
6. Бер үк исемдәге кеше
7. Җөмләдә исем белән белдерелгән сүзне ачыклап килә торган иярчен кисәк
8. Әкият герое, фарсы сүзе
9. *Хөр, бәйсез* сүзенең синонимы
10. *Аңлы, зиһенле* дигәнне белдерә торган сыйфат

11. Мөстәкыйль сүз төркеме
12. Аныклагыч тарафыннан ачыкланып килә торган сүз
13. *Кыйммәтле*нең антонимы
14. Нәрсәнең дә булса үзенә хаслап кушылган исем, термин
15. *Аваздаш* сүзенең синонимы

**VI .Җөмләдәге һәр сүзнең татар теленең кайсы орфографик принцибына нигезләнеп язылуын күрсәтегез.** /Определите правописание каждого слова по орфографическим принципам татарского языка. (10 баллов).

**Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан боргаланып-боргаланып аккан җирендә үзенең зурлыгы, йортларының төзеклеге белән кечерәк шәһәргә охшашлы бер авыл бар...**

**VII. Татар теленең диалектлары турында ниләр беләсез? Әдәби тел диалектлардан ниләр белән аерыла? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. /** Что Вы знаете о диалектах татарского языка? В чем отличия литературного языка от диалектов? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами (15 баллов).

**VIII. "Матур әдәбият әсәре уку – хезмәтме яки ялмы?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша язгыз.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Чтение литературного произведения – труд или отдых?" . (20 баллов)

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________ Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2015-2016 учебный год**
**9 класс**

**I. Рус телендәге гыйбарәләрнең татарча әйтелешен языгыз.** / Напишите выражения, соответствующие русским.(10 баллов).

1) **Была не была** - Беткән баш беткән
2) **В том-то и дело** - Шул шул. -
3) **Все прекрасно** - ал да гөл
4) **Делай с умом** - баш белән эш ит
5) **Ничего особенного** - . Әллә ни түгел.
6) **Приятного аппетита** - Ашларыгыз тәмле булсын
7) **С удовольствием** - Бик рәхәтләнеп. –
8) **Сдержи слово** - әйткән сүздә тор
9) **Скажи откровенно** - ачыктан-ачык әйт
10) **Черт знает** - әллә тагы

**II. Күп нокталар урынына тиешле кушымчаларны куегыз.**/ Вместо многоточий вставьте нужные окончания (5 баллов).

2016 нчы елда Татарстанда 95 мәктәп һәм 52 мәктәп**кәчә** белем бирү учреждение**сен** төзекләндерү планлаштырылган. ТР Дәүләт торак инспекция**се** мәгълүматларына караганда, 2015 елда 42 муниципаль районда капиталь ремонт**лана** торган күп фатирлы йортларда инспекция тикшерүе үткәрелгән. 2016 елда балаларны савыктыру лагерь**ларының** 9 ында капиталь ремонт ясау планлаштырылган. *(вакытлы матбугаттан.)*

**III. Бирелгән тексттан 5пар антонимны табып язып алыгыз.** / Выпишите из текста 5 пар антонимов. (10 баллов)

...Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шул чаклы сиздерә дә башлар икән. Кичен ни көтәсе инде?! Гаҗәп! Хәтта төне дә җиңеллек китермәде – суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан исен аңкытып, һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Менә өч атна инде әле яңгыр тамганы юк. Температура көндезен утыздан артып китә, төннәрен егермедән дә төшми диярлек. Бер кат җәймә генә ябынып ятсаң да йоклап китә алмыйча азапланып бетәсең, мендәреңнең салкынчарак җирен эзләп, аны кат-кат әйләндерергә мәҗбүр буласың. Кышкы суыктан да әшәкерәк икән ул бөркү эсселек!.. (**Ә.Еники** *буенча)*

Җавап: **көне-төне, иртәнге сәгать-кичен, көндезен-төннәрен, суык-эсселек, һаман- әле**

**IV. Һәр җөмләгә тулы билгеләмә бирегез.** / Дайте полное определение каждому предложению. (10 баллов)

1) Ул арада чәй дә кайнап чыга. 2) Табын янына утырасың, табыннан җылылык, нур бөркелә. 3) Каян килә ул нур, ул җылылык? 4) Тәрәзә төбендәге гөлләрдәнме? 5) Әллә инде пар бөркеп утырган самавырданмы? 6) Белмәссең... 7) Ә күңелдә әнә шул җылылыгы, нуры белән бергә моң да бар. 8)Әйтү, аңлату мөмкин булмаган моң газаплый. 9) Шуны куарга, онытырга теләгәндәй, сүз башлыйм.

10) - Һаман дөнья куасыз инде, ә? *(Р. Мөхәммәдиевтан)*
**Һәр җөмләгә бирелгән билгеләмә 1 балл белән бәяләнә.**

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов)

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | А | й | | | | | | | | |
| 2 | А | б | ы | й | | | | | | |
| 3 | А | б | х | а | з | | | | | |
| 4 | А | в | а | з | | | | | | |
| 5 | А | в | т | о | р | | | | | |
| 6 | А | д | а | ш | | | | | | |
| 7 | А | е | р | г | ы | ч | | | | |
| 8 | А | ж | д | а | һ | а | | | | |
| 9 | А | з | а | т | | | | | | |
| 10 | А | к | ы | л | л | ы | | | | |
| 11 | А | л | м | а | ш | л | ы | к | | |
| 12 | А | н | ы | к | л | а | н | м | ы | ш |
| 13 | А | р | з | а | н | л | ы | | | |
| 14 | А | т | а | м | а | | | | | |
| 15 | А | һ | ә | ң | д | ә | ш | | | |

**VI .Җөмләдәге һәр сүзнең татар теленең кайсы орфографик принцибына нигезләнеп язылуын күрсәтегез.** /Определите правописание каждого слова по орфографическим принципам татарского языка. (10 баллов).

**Фонетик приципп буенча язылган сүзләр: Агыйделнең, киң, зур, арасыннан, аккан, җирендә, үзенең, зурлыгы, йортларының, белән, кечерәк, шәһәргә, охшашлы, бер,**

**Тарихи-традицион принцип буенча язылган сүзләр: болыннар, таулар, боргаланып-боргаланып, төзеклеге, авыл, бар**

**VII. Татар теленең диалектлары турынданиләр беләсез? Әдәби тел диалектлардан ниләр белән аерыла? Шул турыда языгыз. Фикерегезне мисаллар белән дәлилләгез. /** Что Вы знаете о диалектах татарского языка? В чем отличия литературного языка от диалектов? Напишите об этом. Обоснуйте свое мнение примерами.(15 баллов).

Татар телендәге 3 диалект: көнбатыш, урта һәм кынчыгыш диалектлар турында мәгълүмат бирелергә; диалектларга хас фонетик, лексик һәм грамматик үзенчәлекләр китерелергә һәм мисаллар белән дәлилләнергә тиеш.

**VIII. "Матур әдәбият әсәре уку – хезмәтме яки ялмы?" дигән сорауга җавап биреп, 70 сүздән ким булмаган инша языгыз.** /Напишите сочинение (не менее из 70 слов) ответив на вопрос " Чтение литературного произведения – труд или отдых?" . (20 баллов)

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| *I* | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык дәлил бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 | 3 |

| | | |
|---|---|---|
| | гомуми дәлил бар. | |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 дәлил бар. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>мисал буларак дәлил  язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |

| | | |
|---|---|---|
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ __________________** **Шифр _____________**

(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2015-2016 учебный год**

**10 класс**

**I. Фразеологик гыйбарәләрне татарча языгыз.** / Напишите фразеологические обороты по-татарски (10 баллов).

1) С ним кашу не сваришь – ________________________________________
2) Сломя голову – ________________________________________
3) Стреляный воробей - ________________________________________
4) Сесть на лужу - ________________________________________
5) Уродиться на славу – ________________________________________
6) Попасть пальцем – ________________________________________
7) Пропади оно пропадом – ________________________________________
8) Много воды утекло – ________________________________________
9) Как карась на сковородке – ________________________________________
10) Ни свет ни заря – ________________________________________

**II.Түбәндәге шигъри юлларны кем язган? Авторларның исем һәм фамилиясен языгыз.** / Напишите имя и фамилию авторов этих стихотворений. (5 баллов).

1) Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер,
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

**Җавап**: ________________________________________

2) Туган тел- иң татлы тел,
Туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма –
Туган телне онытма!

**Җавап:**________________________________________

**III. Тотрыклы гыйбарә килеп чыгарлык итеп, исемнәрне бәйләгез һәм мәгънәләрен аңлатыгыз** / Соединяя имена существительные, образуйте фразеологизмы и объясните значение (10 баллов).
уха, туй, йорт, гыйшык, дилбегә, куас, әбәт, лампа.
Сафура ________________________________________
Габделбасыйр________________________________________
Әбуҗаһил________________________________________
Әндри________________________________________
Галәветдин________________________________________

**IV. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз.** / Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении. (10 баллов)

*Әниләрнең хәлләрен исән вакытта белешик.*

*Әниләрнең* - ______________________________

______________________________

______________________________

*Хәлләрен* - ______________________________

______________________________

______________________________

*Исән* - ______________________________

______________________________

______________________________

*Вакытта* - ______________________________

______________________________

______________________________

*Белешик* - ______________________________

______________________________

______________________________

**V. Кроссвордларны чишегез.** /Решити кроссворды (30 баллов)

**А) Синонимнарын табыгыз.**

**1. Абый -**
**2. Авыл –**
**3. Ат -**
**4. Тамак бакасы –**
**5. Гөллек –**
**6. Дустанә -**
**7. Типография –**
**8. Кышкы көнгә -**

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | а | | | | | | | |
| | | | а | | | | | | |
| | | | | а | | | | | |
| | | | | | а | | | | |
| | | | | | | | а | | |
| | | | | | | | а | | |
| | | | | | | | | а | |
| | | | | | | | | | а |

**Б) Парлы сүзнең икенче кисәген табыгыз.**
**1. Ярым-**
**2. Шик-**
**3. Ачлы-**
**4. Яше-**
**5. Кадер-**
**6. Әйләнү-**
**7. Аркылы –**
**8. Бетмәс-**

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

**VI.Татар әдәби теленең фонетик, орфоэпик, орфографик нормалары турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз. /** Напишите о фонетических, орфоэпических, орфографических нормах татарского языка (15 баллов).

**VII. “Сүзнең тарихын шәһәр тарихыннан эзлә” дигән темага топонимнар турында 80 сүздән ким булмаган сочинение языгыз.** /Напишите сочинение (не менее 80 слов) о топонимах на тему “Историю слова ищи в истории города” (20 баллов)

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________** **Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2015-2016 учебный год**

**10 класс**

**I. Фразеологик гыйбарәләрне татарча языгыз. /** Напишите фразеологические обороты по-татарски (10 баллов).

1) С ним кашу не сваришь – аның белән борчак пешми
2) Сломя голову – уңга-сулга карамый
3) Стреляный воробей - шомарган таш
4) Сесть на лужу - көймәсе комга терәлү
5) Уродиться на славу – ишелеп уңу, егылып уңу
6) Попасть пальцем – кыек атып туры тидерү
7) Пропади оно пропадом – ләгънәт суккыры
8) Много воды утекло – биш былтыр
9) Как карась на сковородке – ут капкандай
10) Ни свет ни заря – таң тишегеннән ( әче таңнан)

**II.Түбәндәге шигъри юлларны кем язган? Авторларның исем һәм фамилиясен языгыз. /** Напишите имя и фамилию авторов этих стихотворений. (5 баллов).

1) Кил, өйрән, и туган, бер башка телне,
Бүтән телләр белү – яхшы һөнәрдер,
Катыштырма вәләкин телгә телне,
Тел уйнатмак наданлыктан әсәрдер.

**Җавап**: _ Дәрдемәнд

2) Туган тел- иң татлы тел,
Туган тел – иң тәмле тел.
Тәмле дип, телең йотма –
Туган телне онытма!

**Җавап:**_ Ш.Галиев

**III. Тотрыклы гыйбарә килеп чыгарлык итеп, исемнәрне бәйләгез һәм мәгънәләрен аңлатыгыз /** Соединяя имена существительные, образуйте фразеологизмы и объясните значение (10 баллов).
1) Сафура туе – столпотворение - бик зур шау-шу ыгы-зыгы, чамасыз ыгы-зыгы, бик зур тәртипсезлек, мәхшәр
2) Габделбасыйр гыйшкы – сентиментальная любовь – артык төче мәхәббәт
3) Әбуҗаһил куасы – опьяняющий напиток – исерткеч эчемлек
4) Әндри әбәте – полдник, второй завтрак - төшке аштан соң ашала торган җиңел аш
5) Галәветдин лампасы - Лампа Аладдина- талисман, выполняющий все желания своего владельца

**IV. Җөмләнең һәр сүзенә морфологик анализ ясап языгыз.** / Сделайте морфологический анализ каждого слова в этом предложении. (10 баллов)
*Әниләрнең хәлләрен исән вакытта белешик.*

Һәр сүзгә дөрес итеп анализ ясау (орфографик хаталарсыз) – 2 балл

**V. Кроссвордларны чишегез.** /Решити кроссворды (30 баллов)
**А) Синонимнарын табыгыз.**
**1. Абый - ага**
**2. Авыл – кала**
**3. Ат - алаша**
**4. Тамак бакасы – ангина**
**5. Гөллек – гөлбакча**
**6. Дустанә - дусларча**
**7. Типография – басмаханә**
**8. Кышкы көнгә -кышкылыкка**

**Б) Парлы сүзнең икенче кисәген табыгыз.**
**1. Ярым-йорты**
**2. Шик-шөбһә**
**3. Ачлы-туклы**
**4. Яше-карты**
**5. Кадер-хөрмәт**
**6. Әйләнү-тулгану**
**7. Аркылы –торкылы**
**8. Бетмәс-төкәнмәс**

**VI.Татар әдәби теленең фонетик, орфоэпик, орфографик нормалары турында языгыз. Җавабыгызны мисаллар белән аңлатыгыз.** / Напишите о фонетических, орфоэпических, орфографических нормах татарского языка (15 баллов).
Татар әдәби теленең фонетик нормаларын язу – 5 балл
Татар әдәби теленең орфоэпик нормаларын язу – 5 балл
Татар әдәби теленең орфографик нормаларын язу – 5 балл
Фонетик нормалар – басымның дөрес куелышын аңлату, сингармонизм законы, хәрефләрнең укылыш үзенчәлекләре
Татар орфоэпиясе — татар телендә нормага салынган әдәби әйтелеш кагыйдәләрнең җыелмасы.
Татар милли әдәби телендә әйтелеш нормалары тел формалашу һәм үсеш дәвамында урнашалар, XIX гасыр ахырында — XX гасыр башында тәмамланалар. Татар теленең орфоэпиясе урта диалектның казан арты сөйләшенә нигезләнгән дип санала. Казан күп гасырлар буе татар халкының мәдәни, сәяси үзәге булып килгән, шуңа күрә казан татарларының сөйләше башкалар өчен үрнәк булып килгән. 1905 елгы инкыйлабтан соң татар әдәби әйтелеше кагыйдәләре турында җитди уйланулар башлана. Татар матбугаты зур үсеш ала, уртак нормалар кирәк була. Бәхәс озак еллар дәвам итә. Татар милли әдәби теле гомумхалык нормаларына нигезләнеп үсә. Татар теленең орфоэпик нормалары түбәндәге принципларга корылган: Орфоэпия гомумхалык телендәге әйтелеш нормаларына нигезләнә. Теге яки бу нормаларның, сүзләрнең әдәбиятта беркетелгән булулары һәм эстетик көчле

булуы кирәк. Әдәби тел орфографисендә морфологик нигездә язылыш нормалары орфоэпиядә дә саклана.
Рус теленнән һәм аның аша башка телләрдән кергән сүзләр әйтелешләре рус орфоэпиясе нормаларына охшаш була. Искәрмә: борынгы үзгәргән алынмалар. Хәзерге татар орфоэпиясе гадиләшү юнәлешендә хәрәкәт итә.
Татар орфографиясе түбәндәге принципларга нигезләнә.
Фонетик принцип – сүзне ишетелгәнчә язу. Мәсәлән, өзелгән, ерак, иләк. Татар телендә сүзләр, башлыча, фонетик принцип буенча языла. Шуңа күрә телебездәге күп кенә фонетик закончалыклар, аваз үзгәрешләре язуда да чагылыш таба. Мәсәлән, татар телендә кушымчаларның калын һәм нечкә вариантлары, кайберләренең яңгырау һәм саңгырау тартыкларга башланган вариантлары бар.
Морфологик принцип – сүзләрнең мәгънәле кисәкләре (морфемаларның) бөтенлеген саклап язу. Бу принцип буенча язганда, әйтелештәге үзгәрешләр язылышта чагылыш тапмый. Мәсәлән, [тоссос] – тозсыз, [умбиш] – унбиш. Җанлы сөйләмдә нинди генә үзгәрешләр булса да, сүз һәм кушымчаларның баштагы язылышы саклана. Рус теле орфографиясе морфологик принципка нигезләнә.
Тарихи-традицион принцип – сүзләрнең элекке язылышын саклап язу. Инглиз һәм француз телләре орфографиясе әлеге принципка нигезләнә, шуңа күрә бу телләрдә әйтелеш белән язылыш арасында зур аерма бар. Татар телендә бу принцип гарәп хәрефләре белән язуда төп урынны тоткан. Хәзерге орфографиядә бу принцип цифрлар белән язылган саннар янында кушымчалар язу үзенчәлегендә чагылыш таба таба. Мәсәлән, алар элек тә сызыкча аша язылмаган, хәзер дә сызыкчасыз языла: 23 әр кеше, 30 лап укучы, температура 0° тан түбән.
График принцип – рус-европа телләреннән кергән сүзләрне, кайбер гарәп-фарсы алынмаларын шул телдәгечә язу: сәлам, һәлак, телефон, троллейбус. Ләкин телебезгә күп еллар элек (күпчелек очракта 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәрге чорда) кергән сүзләр татар теле кагыйдәләренә нигезләнеп әйтелә һәм шул әйтелешкә нигезләнеп языла: бүрәнә, эшләпә.
Дифференциаль принцип – телдәге омонимик очракларны аеру өчен, сүзләрне төрлечә язу. Мәсәлән, ак сакал (нинди сакал?) – сыйфат һәм исемнән торган сүзтезмә, аксакал (кем?) – исем сүз төркеменә керә торган кушма сүз.
Экономия принцибы – урынга экономия ясау һәм тиз язу өчен, күпчелек кешегә аңлаешлы сүзләрне кыскартып язу. Мәсәлән, һ.б., һ.б.ш., БМО, ТР.

**VII. "Сүзнең тарихын шәһәр тарихыннан эзлә" дигән темага топонимнар турында 80 сүздән ким булмаган сочинение языгыз.** /Напишите сочинение (не менее 80 слов) о топонимах на тему "Историю слова ищи в истории города" (20 баллов)

| № | Сочинениене бәяләү критерийлары | Баллар |
|---|---|---|
| ***I*** | ***Иншаның эчтәлеге*** | |
| | Язманың эчтәлеге темага туры килә. Эчтәлеге тулысынча ачылган. Икедән артык топоним турында мәгълүмат бирелгән. | 4 |
| | Язманың эчтәлеге, нигездә, темага туры килә. Эчтәлеге ачылган. 1-2 топоним турында мәгълүмат бар. | 3 |
| | Язманың эчтәлеген бирүдә җитди ялгышлар бар. 1 топоним турында гына язылган. | 2 |
| | Язманың эчтәлеге ачылмаган<br>**яки**<br>Топонимнар турында язылмаган. | 0 |
| ***II*** | ***Иншаның тел ягы*** | |
| | **Язманың мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге, язу эзлеклелеге** | |

| | | |
|---|---|---|
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана:<br>– логик хаталар юк, язуда эзлеклелек бозылмаган;<br>– абзацларга бүленештә хаталар юк. | 2 |
| | Эш мәгънәви бөтенлеге, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерлана,<br>**ләкин**<br>1 логик хатасы бар,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **1** урында хата бар. | 1 |
| | Язмада сөйләм үстерүгә омтылыш бар,<br>**ләкин**<br>логик хаталарның саны 1 дән артык,<br>**һәм/яки**<br>абзацларга бүленештә **2** урында хата бар. | 0 |
| | **Төгәллек һәм сөйләм матурлыгы** | |
| | Язмада фикер төгәл, төрле грамматик формалар кулланылган. | 2 |
| | Язмада фикер төгәл,<br>**Ләкин** бер генә төрле сөйләм калыпларыннан файдаланылган,<br>**яки**<br>язмада төрле грамматик формалар кулланылган,<br>**ләкин** фикер төгәллеге бозылган. | 1 |
| | Сүз байлыгыннан тиешенчә файдалана алмаган, бер үк төрле җөмлә калыпларын гына кулланган. | 0 |
| ***III*** | ***Грамоталылык*** | |
| | **Орфографик нормаларның үтәлеше** | |
| | Орфографик хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | Хатасы 2 дән артык түгел. | 2 |
| | 3-4 хата җибәрелгән | 1 |
| | Хаталарының саны 4 тән артык | 0 |
| | **Пунктуацион нормаларның үтәлеше** | |
| | Пунктуацион хаталары юк (яки тупас булмаган 1 хатасы бар). | 3 |
| | 1-3 хатасы бар. | 2 |
| | 4-5 хатасы бар. | 1 |
| | Хаталарының саны 5 тән артык | 0 |
| | **Тел нормаларының үтәлеше** | |
| | Грамматик хаталары юк | 2 |
| | 1–2 хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны 2 дән артык | 0 |
| | **Сөйләм нормаларының үтәлеше** | |
| | Сөйләмгә кагылышлы 1 генә хатасы бар | 2 |
| | **2–3** хатасы бар | 1 |
| | Хаталарының саны **3** тән артык | 0 |
| | **Этикага кагылышлы нормаларның үтәлеше** | |
| | Этикага кагылышлы хаталары юк | 1 |
| | Хаталары бар (1 һәм 1дән күбрәк) | 0 |
| | **Язмада фактларны бирүдәге төгәллекнең үтәлеше** | |
| | Фактик хаталары юк. | 1 |
| | Фактик хаталары бар. | 0 |
| **Язма эш өчен максималь балл** | | **20** |

*Исправления не допускаются*

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ ___________________ Шифр _____________**
(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2015-2016 учебный год**
**11 класс**

**I. Татар һәм рус телендәге фразеологик гыйбарәләрне Б графасында цифрлар куеп тәңгәлләштерегез.** / Напишите в графу Б цифры соответствия фразеологических оборотов на татарском и русском языках (10 баллов).

| А | | Б | |
|---|---|---|---|
| 1 | күңелдән белү | | к черту на кулички |
| 2 | табан ялтырату | | из рук вон плохо |
| 3 | дүрт куллап | | одним словом |
| 4 | кылын тартып карау | | знать назубок |
| 5 | балтасы суга төшкән кебек | | как в воду опущенный |
| 6 | җәһәннәм астына | | закинуть удочку |
| 7 | озын сүзнең кыскасы | | катиться колбасой |
| 8 | санга санамау | | обеими руками |
| 9 | кулга алырлык түгел | | задать жару |
| 10 | утлы табага бастыру | | в грош не ставить |

**II. Күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз** / Вместо многоточий вставьте нужные буквы (5 баллов).

Мөрәҗәг...тьтә язылганча, мө...ере булмаган ...дәмнәр гыйб...дәтханәгә кертелми икән. Моны Гәүһәр рух... зәгыйф...лекнең бер билгесе дип кабул итте. "Г...иләм исән-сау булсын, - дип уйлады ул, төн...якта каралып торган мәһ...бәт бинага карап, - калганын күз күрер. Вәг...дә - иман, диләр бит." *(вакытлы матб.)*

**III. Бирелгән тексттан гарәп-фарсы алынмаларын язып алыгыз.** / Выпишите из текста арабо-персидские заимствования. (10 баллов)

Әти солдат тормышын сагына, буш вакыты булган саен безгә солдат чагында күргәннәрен сөйли, армиядә алып барган көндәлек дәфтәреннән җырлар укый иде. Аның солдаттан алып кайткан берничә истәлек әйберсе бар. Шуларның берсе - солдат уставы. Бу китапка патша нәселенә исәнлек теләп догалар, гарнизон хезмәте, строй әзерлеге, сәяси әзерлек буенча главалар теркәлгән. Бу устав миндә кадерле мирас булып саклана. (*М. Мәһдиев буенча)*

______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

**IV. Җөмләдәге тыныш билгеләренең ни өчен куелуын аңлатыгыз.** / Объясните, по каким правилам поставлены знаки препинания в предложении. (10 баллов)

Актарына торгач,(1) тагы бер хикмәтле әйбер табылды:(2) бу - (3) аталарының яшь чагында тагып йөргән кыска саплы,(4) күн чуклы,(5) өч җәпле,(6) һәр җәбенең очында көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде (7) *(Әмирхан Еники)*

**1)**____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________
**2)**____________________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

3)________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

4)________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

5)________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

6)________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

7)________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

__________________________________________________________________________

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов)




**Горизонталь буенча:**

1. Төшенчә һәм предметларны төгәл атый торган бер мәгънәле сүз яисә сүзтезмә. 3. Зат я предметның эшен, хәрәкәтен, хәлен, торышын белдерә торган сүзләр. 5. Мәгънәләре ягыннан тәңгәл килгән яки якын торган сүзләр. 9. Телдәге авазларның бер төре. 12. Ике яки икедән артык хәбәрлеге булган җөмлә. 13. Җөмләдә баш килеш мәгънәсендәге сүз белән бирелеп, бер җөмлә кисәгенә дә буйсынмыйча, хәбәр белән генә бәйләнеп килгән баш кисәк. 14. Исем, сыйфат, рәвеш, сан кебек сүз төркемнәрен алмаштырып килә ала торган сүз төркеме. 15. Предмет һәм затларны белдерә торган сүз төркеме.

**Вертикаль буенча:**

2. Сөйләмдә тавышның хәрәкәте. 4. Сүзнең килеп чыгышын һәм мәгънә үсешен өйрәнә торган фән. 6. Сүзләрне төзү өчен хезмәт итә торган бүтән бүленмәүче иң кечкенә аваз берәмлеге. 7. Мәгънәләре буенча капма-каршы сүзләр. 8. Кешенең эчке кичерешләрен, хисләрен, тойгыларын һәм ихтыярын белдерүче сүзләр. 10. Телдәге авазларның бер төре. 11. Исем белән белдерелгән теләсә нинди җөмлә кисәген ачыклаган иярчен кисәк. 16. Әйбернең санын, исәбен, микъдарын белдерә торган сүзләр.

**VI. Муса Җәлилнең шигыре килеп чыгарлык итеп, калын хәреф белән бирелгән сүзләрне җәя эчендә соралган рәвештә төрләндерегез һәм бер-берсенә бәйләгез** /Воспользуясь подсказками в скобках, склоняйте и свяжите выделенные слова таким образом, чтобы в итоге получилось четверостишие Мусы Джалиля. (15 баллов).

1) **батыр** (*исем, берлек санда баш килештә*), **үл-** (*3 зат берлектәге хикәя фигыль, төп юнәлештә*), **үл-** (*киләчәк заман сыйфат фигыль, юклыкта, төп юнәлештә*), **ат** (*исем, берлек санда баш килештә*), **ал-** (*1 формалы хәл фигыль, төп юнәлештә*)

2) **батырлык** (*исем, күплек санда баш килештә*), **белән** (*бәйлек*), **макта-** (*1 формалы хәл фигыль, кайтым юнәлешендә*)

3) **исем-** (*исем, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән, баш килештә*), **кал-** (*3 зат берлектәге боерык фигыль*), **үз-** (*алмашлык, 2 зат берлектәге тартым белән төрләнгән*), **үл-** (*шарт фигыль, 2 зат берлектә*), **дә** (*кисәкчә*)

4) **тарих** (*исем, күплек санда, урын-вакыт килешендә*), **ук-** (*1 формалы хәл фигыль, төп юнәлештә*), **ятлар-** (*җыелма күплек кушымчасы белән ясалып исемләшкән сыйфат фигыль*)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**VII. Телләрнең килеп чыгышы турында языгыз. Моногенизм һәм полигенизм теорияләрен аңлатыгыз. Алтай бердәмлегенә һәм урал-алтай тел гаиләсә кергән телләрне санагыз.** / Напишите о происхождении языка. Объясните теории моногенизма и полигенизма. Перечислите языки, входящие в алтайскую общность и урало-алтайскую языковую семью (15 баллов).

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

**VIII. Татар теленнән программалар һәм дәреслекләр төзегән тел галимнәренең берсе турында "Галим булсаң, галәм синеке" дигән темага 100 сүздән ким булмаган инша языгыз.** /Напишите сочинение (не менее из 100 слов) на тему "Властелин Вселенной - ученый" об ученых-языковедах, составителях учебников и программ по татарскому языку. (20 баллов)

*Исправления не допускаются*

**Итоговый балл ________ __________________** **Шифр _____________**

(подпись председателя жюри)

**Межрегиональная предметная олимпиада Казанского федерального университета**
**по предмету «Татарский язык»**
**Очный тур**
**2015-2016 учебный год**
**11 класс**

**I. Татар һәм рус телендәге фразеологик гыйбарәләрне Б графасында цифрлар куеп тәңгәлләштерегез.** / Напишите в графу Б цифры соответствия фразеологических оборотов на татарском и русском языках (10 баллов).

| А | | Б | |
|---|---|---|---|
| 1 | күңелдән белү | 6 | к черту на кулички |
| 2 | табан ялтырату | 9 | из рук вон плохо |
| 3 | дүрт куллап | 7 | одним словом |
| 4 | кылын тартып карау | 1 | знать назубок |
| 5 | балтасы суга төшкән кебек | 5 | как в воду опущенный |
| 6 | җәһәннәм астына | 4 | закинуть удочку |
| 7 | озын сүзнең кыскасы | 2 | катиться колбасой |
| 8 | санга санамау | 3 | обеими руками |
| 9 | кулга алырлык түгел | 10 | задать жару |
| 10 | утлы табага бастыру | 8 | в грош не ставить |

**II. Күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз** / Вместо многоточий вставьте нужные буквы (5 баллов).

**Җавап:** МөрәҗәгАтьтә язылганча, мөҺере булмаган Адәмнәр гыйбАдәтханәгә кертелми икән. Моны Гәүһәр рухИ зәгыйфЬлекнең бер билгесе дип кабул итте. "ГАиләм исән-сау булсын, - дип уйлады ул, төнЬякта каралып торган мәһАбәт бинага карап, - калганын күз күрер. ВәгЪдә - иман, диләр бит." *(вакытлы матб.)*

*Дөрес билгеләнгән һәр хәреф - 0,5 б.*

**III. Бирелгән тексттан гарәп-фарсы алынмаларын язып алыгыз.** / Выпишите из текста арабо-персидские заимствования. (10 баллов)

Әти солдат тормышын сагына, буш вакыты булган саен безгә солдат чагында күргәннәрен сөйли, армиядә алып барган көндәлек дәфтәреннән җырлар укый иде. Аның солдаттан алып кайткан берничә истәлек әйберсе бар. Шуларның берсе - солдат уставы. Бу китапка патша нәселенә исәнлек теләп догалар, гарнизон хезмәте, строй әзерлеге, сәяси әзерлек буенча главалар теркәлгән. Бу устав миндә кадерле мирас булып саклана. (*М. Мәһдиев буенча)*

**Җавап:** вакыты, дәфтәреннән, китапка, патша, нәселенә, догалар, хезмәте, сәяси, кадерле, мирас *(табылган һәр сүз - 1 б.)*

**IV. Җөмләдәге тыныш билгеләренең ни өчен куелуын аңлатыгыз.** / Объясните, по каким правилам поставлены знаки препинания в предложении. (10 баллов)

Актарына торгач,(1) тагы бер хикмәтле әйбер табылды:(2) бу - (3) аталарының яшь чагында тагып йөргән кыска саплы,(4) күн чуклы,(5) өч җәпле,(6) һәр җәбенең очында көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде (7) *(Әмирхан Еники)*

(1) Хәл фигыльнең -гач/-гәч формасы белән белдерелгән вакыт хәле, хәбәр белән янәшә килмәсә, аерымлана. (2 балл)
(2) Күтәрү интонациясе белән бәйләнгән баш җөмлә алдан килсә, аннан соң ике нокта куела. (2 балл)
(3) Ия алмашлык белән белдерелеп, аңа аерым басым ясалса, хәбәр исем белән бирелсә, алар арасына сызык куела. (2 балл)
(4), (5), (6) Тиңдәш кисәкләр арасына өтер куела. (2 балл)
(7) Хикәя җөмлә ахырында нокта билгесе куела. (2 балл)

**V. Башваткычны чишегез.** / Решите кроссворд. (15 баллов)




**VI. Муса Җәлилнең шигыре килеп чыгарлык итеп, калын хәреф белән бирелгән сүзләрне җәя эчендә соралган рәвештә төрләндерегез һәм бер-берсенә бәйләгез** /Воспользуясь подсказками в скобках, склоняйте и свяжите выделенные слова таким образом, чтобы в итоге получилось четверостишие Мусы Джалиля. (15 баллов).
**Җавап:**
Батыр үлә, үлмәс ат алып, (2 б)
Батырлыклар белән макталып. (4 б)
Исемең калсын, үзең үлсәң дә, (2 б)
Тарихларда укып ятларлык *(М. Җәлил)* (2 б)

**VII. Телләрнең килеп чыгышы турында языгыз. Моногенизм һәм полигенизм теорияләрен аңлатыгыз. Алтай бердәмлегенә һәм урал-алтай тел гаиләсә кергән телләрне санагыз.** / Напишите о происхождении языка. Объясните теории моногенизма и полигенизма. Перечислите языки, входящие в алтайскую общность и урало-алтайскую языковую семью (15 баллов).

**Җавап:**

Телләрнең килеп чыгышы турында бик күп теорияләр бар: дини тәгълимат, балалар теле, ымлыклар, аваз ияртемнәре теориясе, хезмәт тавышлары теориясе һ.б. Шулар арасында моногенизм һәм полигенизм теорияләре фәнни яктан кызыклы дип бәяләнә. Беренчесе - **моногенизм** теориясе - барлык телләр дә бер телдән үсеп чыкканнар, бу телдә сөйләшүче халыклар төрле җирләргә күченеп утыру нәтиҗәсендә телләр нигез телдән шактый ераклашкан, үзгәргән, шул рәвешле җирдә төрле телләр һәм халыклар барлыкка килгән. Икенче теория - **полигенизм** теориясе буенча, телләр җир шарының төрле урыннарында барлыкка килгәннәр һәм үскәннәр, шуңа күрә алар бер-берсенә охшамаган һәм борынгылыгы-яңалыгы белән аерылып торалар.

**Моногенизм** теориясе телләрнең кардәшлегенә таяна һәм телләрне бердәмлекләргә, тел гаиләләренә төркемләп өйрәнә. Төрки, монгол, тунгус-маньчжур, корея һәм япон телләре бер нигез телдән барлыкка килгәннәр һәм кайсыдыр этапта бер тел бердәмлеген тәшкил иткәннәр. Бу берлек фәндә **алтай телләре** бердәмлеге дип атала. Алтай тел бердәмлеге тагы да ерак чорларда урал-алтай телләре белән бер нигез телгә барып тоташкан. Бу берлекне **урал-алтай тел гаиләлеге** дип атыйлар. Бу төркемгә алтай бердәмлегенә караган телләрдән тыш, фин-угор, самодий телләре дә кергән.

Иң борынгы тел бердәмлеге исә **ностратик** тел гаиләсе дип атала. Моңа һинд-европа, урал-алтай, афразия, дравидий һәм картвель телләре төркемнәре карый.

**VIII. Татар теленнән программалар һәм дәреслекләр төзегән тел галимнәренең берсе турында "Галим булсаң, галәм синеке" дигән темага 100 сүздән ким булмаган инша языгыз.** /Напишите сочинение (не менее из 100 слов) на тему "Властелин Вселенной - ученый" об ученых-языковедах, составителях учебников и программ по татарскому языку. (20 баллов)

**Иншаны бәяләү критерийлары:**

1. Темага туры килү дәрәҗәсе *(темага туры килмәгән эшләр бәяләнми)*. - 2 б.
2. Темада чагылган проблеманы аргументацияләү осталыгы. Укучының алдан үзләштергән әдәби яисә фәнни материалны куллана алу дәрәҗәсе. - 6 б.
3. Иншаның композицион бөтенлеге һәм логик эзлеклелеге. - 4 б.
4. Укучының язма сөйләм сыйфаты (стиль ягы). - 4 б.
5. Грамоталылык. - 4 б.